ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06.09.2024 с.Старое Дрожжаное № 372

2024 елның III-IV кварталында торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача бәясен раслау турында

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2024 елның 18 июнендәге 390/пр номерлы «2024 елның беренче яртыеллыгына Россия Федерациясе буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының бәясе нормативы һәм 2024 елның 3 кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елның III-IV кварталына Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә гражданнарның торак шартларын яхшырту чараларын үткәрүгә социаль түләүләр күләме исәбеннән гомуми торак мәйданының бер квадрат метрының бәясен, «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру кысаларында авыл җирендә яшәүче, яшь гаиләләр һәм яшь белгечләрнең Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән, 31 800 сум 00 тиен күләмендә расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге начальнигы Р.Р. Вилдановка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.Р. Измайлов